СОВЕТ
ЯНГА - САЛСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.18, с. Янга-Сала,
Арский муниципальный район, 422011

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢАСАЛА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 18 йорт, Яңасала авылы,
Арча муниципаль районы, 422011

Тел. (84366) 57-2-10, факс (84366) 57-2-10. E-mail: Yns.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

**Яңасала авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**22 ноябрь 2018 ел** **№15**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советының 2014 елның 2 июнендәге 57.1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе һәм гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турындагы Нигезләмәдә.

1) 5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1 Үзара салым акчаларын җыю тәртибе башкарма комитет карары белән билгеләнә».

2) 5.2-5.4 пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Арча районы, Яңасала авылы, Үзәк ур., 20 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Каенсар авылы, Урта ур., 25 йорт.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңасала авыл җирлеге башлыгы А.И. Сафин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ЯНГА-САЛСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
СОВЕТ ЯНГА-САЛСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609003024